СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Тел.: (84379) 30-1-48, факс (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ 24.09.2018

КАРАР № 46-209

с. Шеланга

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча Шилангы авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Шилангы авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, Шилангы авыл җирлеге Советының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 20.09.2018 ел, № 45-205 карары, Шилангы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында»20.09.2018 ел, № 136 карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. 2018 елның 18 ноябренә Шилангы авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне раслау:

«Сез 2019 елда үзара салым кертүгә җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр авыл кешесеннән 350 сум күләмендә ризамы һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтәсезме:
- Берек авылы Үзәк урамы буенча юл төзелеше;
- Кызыл Байрак поселогы зиратын төзекләндерү;
- Нариман авылы Эшче урамы буенча юлын төзү;
- Шилангы авылы зиратын һәм чишмәсен төзекләндерү;
- Яңа Юл бистәсе территориясендә балалар мәйданчыгы төзелеше.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында бастырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль

районының рәсми сайтында, Шылаңгы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров